ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт программалары» сүзләрен «дәүләт программалары һәм муниципаль программалар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы шул исәптән бюджет законнарында каралган тиешле Россия Федерациясе дәүләт программалары, Татарстан Республикасы дәүләт программалары, муниципаль программалар кысаларында гамәлгә ашырыла.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:
«$2^1$. Мәдәни мирас объектларын әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән программаларга өстенлекле тәртиптә кертү өчен критерийлар Федераль законда билгеләнә. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, муниципаль программаларны эшләгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары мондый программаларга мәдәни мирас объектларын өстенлекле тәртиптә кертү өчен өстәмә

критерийлар билгеләргә мөмкин, шул ук вакытта Федераль законда каралган критерийлар төшереп калдырылмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 107-ТРЗ